**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 март 2014 ел Казан шәһәре № 7-7/т

***Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы Норлат шәһәренең җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга кушымта нигезендә, Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы Норлат шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларын билгеләргә.
2. “Татарстан Республикасының Норлат шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларын билгеләү турында” 23 июнь, 2010 ел, № 7-13/т Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28 март 2014 ел № 7-7/т карарына кушымта

## Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы Норлат шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум). | |
|---|---|---|
| | Транспорт салонында билет алган чакта | 50 тапкыр һәм аннан күбрәк бару озак вакыт куллану билеты белән бер тапкыр утырып бару өчен түләм[1] |
| Автобус | 15,00 | 10,00 |

<1> Билгеле бер вакыт аралагында билгеләнгән тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж алып бару өчен транспортта бару бәясеннән аерым өстәп түләнелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге